ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2022 г. Заинск № 72

**«Об утверждении муниципальной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Заинского муниципального района на 2022-2043 годы»**

В целях реализации Жилищного кодекса Российской Федерации, Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», руководствуясь Уставом Заинского муниципального района Республики Татарстан

**постановляет:**

1. Утвердить муниципальную программу капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Заинского муниципального района Республики Татарстан на 2022-2043 годы (приложение).
2. Признать утратившими силу:

2.1. Постановление Исполнительного комитета Заинского муниципального района от 24.05.2017 № 936 «Об утверждении региональной адресной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Заинского муниципального района»;

2.2. Постановление Исполнительного комитета Заинского муниципального района от 29.03.2018 № 484 «О внесении изменении в Постановление Исполнительного комитета Заинского муниципального района от 24.05.2017 № 936 «Об утверждении региональной адресной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Заинского муниципального района».

3. Организационному отделу Исполнительного комитета Заинского муниципального района опубликовать настоящее на официальном портале правовой информации pravo.tatarstan.ru и на официальном сайте Заинского муниципального района Республики Татарстан zainsk.tatarstan.ru.

4. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на заместителя Руководителя Исполнительного комитета по инфраструктурному развитию.

**Руководитель**
**Исполнительного комитета** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
8(85558) 07-08-18

Приложение
к постановлению
Руководителя
Исполнительного комитета
Заинского муниципального
района
от 14.02.2022 № 72

# МУНИЦИПАЛЬНЬНАЯ ПРОГРАММА КАПИТАЛЬНОГО РЕМОНТА ОБЩЕГО ИМУЩЕСТВА В МНОГОКВАРТИРНЫХ ДОМАХ, РАСПОЛОЖЕННЫХ НА ТЕРРИТОРИИ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА НА 2022-2043 ГОДЫ

Паспорт программы

| | |
|---|---|
| Наименование программы | Муниципальная программа капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Заинского муниципального района (далее — Программа) |
| Основание принятия решения о разработке Программы | Жилищный кодекс Российской Федерации, Закон Республики Татарстан от 25.06.2013 года №52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» |
| Разработчик Программы | Исполнительный комитет Заинского муниципального района. |
| Цели Программы | Создание безопасных и благоприятных условий проживания граждан. Сохранение, восстановление и повышение качества жилищного фонда, улучшение технического состояния многоквартирных домов, за исключением домов, признанных аварийными подлежащими сносу, а также в случае принятия исполни тельным органом государственной власти или органом местного самоуправления решений об изъятии для государственных или муниципальных нужд земельного участка, на котором расположен многоквартирный дом, и об изъятии каждого жилого помещения в этом многоквартирном доме. |
| Задачи Программы | Эффективное планирование и организация своевременного проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, использование эффективных технических решений и комплексности при проведении капитального ремонта с применением долговечных материалов и ресурсосберегающих технологий. |

| | |
|---|---|
| Сроки реализации Программы | 2022-2043 годы |
| Ожидаемые конечные результаты реализации Программы | Приведение жилищного фонда в соответствие с требованиями законодательства Российской Федерации (в том числе о санитарно-эпидемиологическом благополучии населения, техническом регулировании, защите прав потребителей). |
| Система организации контроля за выполнением Программы | Министерство строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, Государственная жилищная инспекция Республики Татарстан, Исполнительный комитет Заинского муниципального района, Региональный оператор, владелец специального счета осуществляют контроль за реализацией Программы, организуют планирование, взаимодействие, координацию и контроль при реализации Программы. |

## I. Характеристика проблемы

Актуальность принятия настоящей Программы обусловлена рядом социально-экономических факторов. Социальные факторы связаны с низким качеством жилищных услуг и потенциальной аварийностью объектов жилищного фонда, экономические — с высокими эксплуатационными затратами на его содержание.

Решение указанных проблем является приоритетным направлением национального проекта «Доступное и комфортное жилье — гражданам России» в Республике Татарстан и возможно только программными методами, путем проведения комплекса организационных, производственных, социально-экономических и других мероприятий в сроки реализации настоящей Программы, координации деятельности всех исполнителей Программы государственным заказчиком.

## II. Основные цели и задачи, сроки реализации

Основными целями Программы являются:

- сохранение, восстановление и повышение качества жилищного фонда в Заинском муниципальном районе;
- создание безопасных и благоприятных условий проживания граждан.

Основными задачами Программы являются:

- проведение активной агитационно-разъяснительной работы с населением;
- разработка и соблюдение прозрачных и публичных процедур отбора исполнителей Программы;
-использование эффективных технических решений и комплексности при проведении капитального ремонта с применением долговечных материалов и ресурсосберегающих технологий.

Настоящая Программа будет реализована в 2022-2043 годах.

Реализация Программы должна обеспечить безопасными и благоприятными условиями проживания граждан в 219 многоквартирных домах.

## III. Перечень товариществ собственников жилья, управляющих компаний участвующих в Программе

В реализации настоящей Программы участвуют следующие товарищества собственников жилья, управляющие компании Заинского муниципального района:

ООО «УК ЖКХ г.Заинск», ТСЖ «Унайлы йорт», ТСЖ «Доверие», ТСЖ «17 подъездов», ТСЖ «Девятиэтажка», ТСЖ «Иске Зай», ТСЖ «Нефтяник», ТСЖ» Строитель», ТСЖ «Жемчужина».

## IV. Программные мероприятия Основные мероприятия Программы:

проведение с применением долговечных материалов с улучшенными эксплуатационными характеристиками следующих услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирных домах:

ремонт или замена внутридомовых инженерных систем электро-, тепло-, водо снабжения, водоотведения, газоснабжения;

ремонт или замена лифтового оборудования, признанного непригодным для эксплуатации, при необходимости ремонт лифтовых шахт;

ремонт крыш;

ремонт подвальных помещений, относящихся к общему имуществу в многоквартирных домах;

утепление и ремонт фасадов;

установка или замена коллективных (общедомовых) приборов учета потребления ресурсов и узлов управления (тепловой энергии, горячей и холодной воды, электрической энергии, газа);

ремонт фундаментов;

ремонт подъездов в многоквартирном доме;

проведение энергетического обследования многоквартирного дома;

разработка и проведение государственной экспертизы проектной документации (в случае, если подготовка проектной документации необходима в соответствиис законодательном о градостроительной деятельности);

осуществление строительного контроля;

ремонт системы противопожарной защиты многоквартирного дома.

## V. Порядок актуализации Программы Основаниями для актуализации Программы являются:

признание многоквартирного дома, включенного в Программу, в установленном Правительством Российской Федерации порядке аварийным и подлежащим сносу;

механизм реализации краткосрочного (ежегодного) плана реализации Программы;

-размер предельной стоимости проведения капитального ремонта в расчете на один квадратный метр общей площади помещений в многоквартирных домах, включенных в краткосрочный (ежегодный) план реализации Программы;

- иные сведения, подлежащие включению в краткосрочные (ежегодные) планы реализации Программы.

## VI. Условия включения многоквартирных домов в Программу

В Программу включатся все многоквартирные дома, расположенные на территории Республики Татарстан, за исключением многоквартирных домов, признанных в установленном Правительством Российской Федерации порядке аварийными и подлежащими сносу.

Очередность проведения капитального ремонта общего имущества в много квартирных домах определяется в Программе на основании критериев, указанных в

Законе Республики Татарстан от 25.06.2013 № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан».

Перечни подлежащих капитальному ремонту многоквартирных домов указаны в приложении к настоящей Программе.

## VII. Срок принятия решения об определении способа формирования фонда капитального ремонта

Решение об определении способа формирования фонда капитального ремонта должно быть принято и реализовано собственниками помещений в многоквартирном доме в течение двух месяцев после официального опубликования настоящей Программы.

В указанный срок собственники помещений в многоквартирном доме в соответствии с Жилищным кодексом Российской Федерации вправе выбрать один из следующих способов формирования фонда капитального ремонта:

1) перечисление взносов на капитальный ремонт на специальный счет в целях формирования фонда капитального ремонта в виде денежных средств, находящихся на специальном счете;

2) перечисление взносов на капитальный ремонт на счет регионального оператора в целях формирования фонда капитального ремонта в виде обязательственных прав собственников помещений в многоквартирном доме в отношении регионального оператора.

## VIII. Информационное и методическое обеспечение Программы

Успешная реализация Программы в значительной степени зависит от

своевременности, доступности, полноты и качества проводимой

информационно- разъяснительной работы, путем регулярного освещения хода реализации Программы в республиканских, городских и районных средствах массовой информации.

в периодических изданиях (газетах, журналах, в том числе электронных), на радио- и телеканалах;

создания специальных теле- и радиопрограмм для освещения вопросов реформирования жилищно-коммунального хозяйства и проведения капитального ремонта;

поддержания в актуальном состоянии официального сайта Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, органов местного самоуправления;

выпуска и распространения тематических методических и справочных материалов по вопросам реформирования жилищно-коммунального хозяйства и проведения капитального ремонта;

доведения ТСЖ, УК, ЖСК путем размещения на досках объявлений, расположенных в каждом подъезде многоквартирных домов, включенных в Программу, или в пределах земельных участков, на которых находятся такие дома, а также (при наличии) на своих сайтах в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» до граждан информации о планируемых сроках выполнения работ по капитальному ремонту многоквартирного дома.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2022 г. Заинск № 72

**«2022-2043 елларга Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны раслау турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексын, “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2022-2043 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны расларга (кушымта).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. «Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ адреслы программаны раслау турында» 2017 елның 24 маендагы 936 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

2.2. «Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ адреслы программаны раслау турында» 2017 елның 24 маендагы 936 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 29 мартындагы 484 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
8(85558) 07-08-18

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.02. 2022 ел
72 номерлы карарына
кушымта.

**2022-2043 елларга Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программа**

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программа (алга таба – программа) |
| Программаны әзерләү турында карар кабул итү нигезләре | Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны эшләүче | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | Гражданнарның имин һәм уңайлы яшәве өчен шартлар тудыру. Авария хәлендә булу сәбәпле, сүтелергә тиешле дип танылган йортлардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген алу һәм әлеге күпфатирлы йортта һәр торак урынны алу турында карарлар кабул ителгән очрактан тыш, торак фондының сыйфатын саклап калу, торгызу һәм күтәрү, күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту. |
| Программаның бурычлары | Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны нәтиҗәле планлаштыру һәм оештыру, озакка чыдамлы материаллар һәм технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләр һәм комплекслылыкны тәэмин итү. |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2022-2043 еллар |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Торак фондын Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерү (шул исәптән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, техник җайга салу, кулланучылар хокукларын яклау турында). |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты, Региональ оператор, махсус исәп хуҗасы, программаны тормышка ашыруны контрольдә тота, программаны гамәлгә ашырганда планлаштыруны, үзара бәйләнешне, координацияләүне һәм контрольне оештыра. |

## I. Проблеманың характеристикасы

Әлеге программаны кабул итүнең актуальлеге берничә социаль-икътисадый факторга бәйле. Социаль факторлар - торак хезмәтләренең сыйфаты түбән булу һәм торак фонды объектларының потенциаль авария хәлендә булуы, икътисадый фактор - аны тотуга эксплуатация чыгымнарының югары булуы.

Күрсәтелгән проблемаларны хәл итү Татарстан Республикасында «Россия гражданнарына арзанлы һәм уңайлы торак» милли проектының өстенлекле юнәлеше булып тора һәм бу программаны гамәлгә ашыру программа методлары ярдәмендә оештыру, җитештерү, социаль-икътисади һәм башка чаралар комплексын үткәрү, программаны башкаручыларның эшчәнлеген дәүләт заказчысы тарафыннан координацияләү юлы белән генә мөмкин.

## II. Төп максатлар һәм бурычлар, тормышка ашыру сроклары

Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү.

программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

программаны башкаручыларны сайлау буенча үтә күренмәле һәм ачык процедураларны эшләү һәм үтәү;

капиталь ремонт ясауны нәтиҗәле планлаштыру һәм оештыру, озакка чыдамлы материаллар һәм технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны тәэмин итү.

Әлеге программа 2022-2043 елларда гамәлгә ашырылачак.

Программаны гамәлгә ашыру 219 күпфатирлы йортта яшәүче гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге Программа үтәлешенең планлаштырылган күрсәткечләре аңа кушымтада бирелгән.

## III. Программада катнашучы торак милекчеләре ширкәтләре, идарәче компанияләр исемлеге

Әлеге программаны тормышка ашыруда Зәй муниципаль районының түбәндәге торак милекчеләре ширкәтләре, идарәче компанияләре катнаша:

«Зәй шәһәре ТКХ ИК» ҖЧҖ, «Унайлы йорт» ТМШ, «Доверие» ТМШ, «17 подъезд» ТМШ, «Тугыз катлы йорт» ТМШ, «Иске Зәй» ТМШ, «Нефтьче» ТМШ, «Төзүче» ТМШ, «Жемчужина» ТМШ.

## IV. Программаның төп чаралары:

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча түбәндәге хезмәтләрне һәм (яисә) эшләрне яхшыртылган эксплуатация характеристикалары булган озакка чыдамлы материаллар кулланып үткәрү:

йорт эчендәге инженерлык системаларын электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, юынтык суларны чыгару системаларын ремонтлау яисә алмаштыру;

эксплуатацияләү өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазларын ремонтлау яисә алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау;

түбәләрне ремонтлау;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау;

фасадны җылыту һәм ремонтлау;

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслардан файдалануны исәпкә алуның коллектив (гомумйорт) приборларын (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) һәм әлеге ресурслардан файдаланганда идарә итү һәм җайга салу узелларын урнаштыру яисә алмаштыру;

фундаментларны ремонтлау;

күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау;

күпфатирлы йортта энергетика тикшерүе үткәрү;

проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта);

төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

күпфатирлы йортның янгыннан яклау системасын ремонтлау;

## V. Программаны актуальләштерү тәртибе

Программаны актуальләштерү өчен түбәндәгеләр нигез була:

Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә программага кертелгән

күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану;

программаны тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) планын тормышка ашыру механизмы;

- программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планына кертелгән күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының бер квадрат метрына исәпләнгән капиталь ремонт үткәрүнең чик бәясе күләме;

- программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы (еллык) планнарына кертелергә тиешле башка мәгълүматлар.

## VI. Күпфатирлы йортларны программага кертү шартлары

Программага Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортлардан тыш, барлык күпфатирлы йортлар да кертелә.

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау чираты «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән критерийлар нигезендә Программада билгеләнә.

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясалырга тиешле исемлекләр әлеге программаның кушымтасында күрсәтелгән.

## VII. Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын билгеләү турында карар кабул итү вакыты

Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын билгеләү турында карар әлеге программа рәсми басылып чыкканнан соң ике ай эчендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан кабул ителергә һәм гамәлгә ашырылырга тиеш.

Күрсәтелгән вакыт эчендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, капиталь ремонт фондын формалаштыруның түбәндәге ысулларының берсен сайларга хокуклы:

1) капиталь ремонт өчен взносларны махсус исәптәге акчалар рәвешендә капиталь ремонт фондын формалаштыру максатларында махсус счетка күчерү;

2) күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең региональ операторга карата мәҗбүри хокуклары рәвешендә капиталь ремонт фондын формалаштыру максатларында региональ оператор исәбенә капиталь ремонт өчен взносларны күчерү.

## VIII. Программаны мәгълүмати һәм методик яктан тәэмин итү

Программаны уңышлы гамәлгә ашыру шактый дәрәҗәдә республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чараларында Программаны гамәлгә ашыру барышын даими

яктырту юлы белән үткәрелә торган мәгълүмати-аңлату эшенең вакытлы, үтемле, тулы һәм сыйфатлы булуына бәйле:

вакытлы басмаларда (газеталарда, журналларда, шул исәптән электрон басмаларда), радио- һәм телеканалларда;

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру һәм капиталь ремонт уздыру мәсьәләләрен яктырту өчен махсус теле- һәм радиопрограммалар булдыру;

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтын актуаль халәттә тоту;

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча тематик методик һәм белешмә материаллар чыгару һәм тарату;

ТМШ, идарәче компанияләр, ТТК тарафыннан программага кертелгән күпфатирлы йортларның һәр подъездында яисә шундый йортлар урнашкан җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан белдерүләр такталарында урнаштыру юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтларында урнаштыру аша күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау эшләрен башкаруның планлаштырыла торган сроклары турында гражданнарга мәгълүмат җиткерү.